**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**«Шешминка авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге**
**гражданнары җыены**
**КАРАРЫ**

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлегенең Шешминка Крепосте торак пунктында 2026 елда үзара салым кертү турында**

**17 октябрь 2025 ел** **№ 4**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлегенең Шешминка Крепосте торак пунктында гражданнар җыены **КАРАР ИТТЕ:**

1. 2026 елда Шешминка авыл җирлегенең Шешминка Крепосте торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, Луганск халык республикасы һәм Донецк халык республикасы махсус операциясендә булган затлардан, 1 төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге кешеләрдән тыш

2. Алынган чараларны түбәндәге эшләргә җибәрергә:

- **торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү** (юл кырыйларын чабу, кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту) Шешминка Крепосте торак пунктында, ягулык-майлау материаллары һәм трактор өчен запас частьләр сатып алу, хезмәт өчен түләү, кирәкле кораллар, материаллар сатып алу, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкаруның махсус техникасын яллау;
- **электр элемтәләрен тәэмин итү һәм җиһазларның электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен тышкы яктырту урам челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын ремонтлау** (Шешминка Крепосте торак пунктында урам яктырткычларын монтажлау, алыштыру);
- **киртәләрне ремонтлау, кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү** (зиратларны реконструкцияләү, карап тоту, чүп савытлары кую, агач кисү, коры-сарыдан чистарту, инвентарь сатып алу, керү юлларын төзекләндерү, Шешминка Крепосте торак пунктында проект-смета документациясе өчен түләү, югарыда

күрсәтелгән эшләрне башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу, хезмәтләр өчен түләү).

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Шешминка авыл җирлегенең рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Шешминка авыл җирлеге башлыгы А.В.Сидоров